СОВЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail:Kach .Ars@tatar.ru

**Кәче авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

« 18 » декабрь 2020 ел № 13

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 22 октябрендәге 64 номерлы Кәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Прокуратура күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатыннан һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Уставына таянып, Кәче авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2018 елның 22 октябрендәге 64 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«4 статья. Гавами тыңлаулар инициаторлары**

Гавами тыңлаулар халык, Кәче авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык), үз вәкаләтләрен Регламент нигезендә контракт буенча гамәлгә ашыручы Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - БК җитәкчесе) инициативасы белән үткәрелә.»;

2) 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Совет карары белән билгеләнә.

Җирлек башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар җирлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе законнары буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча үткәрелә.»;

3) 6 статьяның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилле нигезләп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм (яисә) башка мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы: Р.Д. Шаһиәхмәтов

СОВЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КАЧЕЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609002856